КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 15 декабрь г.Казань № 1343

Татарстан Республикасында «Нәтиҗәле төбәк» пилот проектын гамәлгә ашыру буенча Координацияләү советы төзү турында

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарында сакчыл җитештерү принципларын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасында «Нәтиҗәле төбәк» пилот проектын гамәлгә ашыру буенча Координацияләү советы төзергә.

2. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

Татарстан Республикасында «Нәтиҗәле төбәк» пилот проектын гамәлгә ашыру буенча Координацияләү советы турында нигезләмә;

Татарстан Республикасында «Нәтиҗәле төбәк» пилот проектын гамәлгә ашыру буенча Координацияләү советы составы.

3. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренә «Нәтиҗәле төбәк» пилот проектын гамәлгә ашыруда катнашырга тәкъдим итәргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин